Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре
2017-2018 уку елы
7 нче сыйныф

Үткәрү вакыты – 90 минут.
Максималь балл – 48.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. [ц] авазының үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) яңгырау, саңгырау пары [щ], тел-теш, авыз тартыгы
ә) саңгырау, яңгырау пары [ж], тел-теш, авыз тартыгы;
б) саңгырау, парсыз, тел-теш, авыз тартыгы
в) саңгырау, парсыз, тел-аңкау, авыз тартыгы

2. Җөмләдәге СТ (сузык+тартык) калыбындагы иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Алтын көз – муллык көзе – җир өстенә канатын җәя.
(Г.Мөхәммәтшин)

а) 1 ә) 2 б) 3 в) 4

3. ***Җанатар*** сүзенең мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) тренер
ә) спорт ярышларын караучы
б) судья
в) спорт ярышларында катнашучы

4. Җөмләдәге санның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Шушы бер-ике көндә кайтып килербез. (Ф.Яруллин)

а) тәртип ә) бүлем б) чама в) җыю

5. Исемләшкән сыйфат кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Үстердек кызыл гөлләр, сокланып үпте җилләр. (З.Мансур)
ә) Гөрләп үсәбез, без – бәхетләләр. (Ә.Ерикәй)
б) Җемелди көз кояшында уттай яфрак һаман да. (Ш.Маннур)
в) Әүвәлге заманда булган, ди, ялкау ике кеше. (Әкият)

6. Калын хәрефләр белән бирелгән алмашлыкка дөрес мәрфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Шуннан *без, әтине сагынган саен, сандыктагы кадерле икмәкне алып карый, караган саен, әтине ныграк сагына торган булдык.* (Ш.Маннапов)

а) күрсәтү алмашлыгы, берлек санда, чыгыш килешендә

ә) III зат алмашлыгы, берлек санда, чыгыш килешендә

б) сорау алмашлыгы, чыгыш килешендә

в) күрсәтү алмашлыгы, күплек санда, чыгыш килешендә

7. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Кошлар агачларда кышлый торган зарарлы бөҗәкләрне чүпли, шуның ***өчен*** *җимлекне бакчага да элеп куярга кирәк. (Календарьдан)*

а) иялек килешен таләп итә торган бәйлек сүз

ә) иялек килешен таләп итә торган бәйлек

б) кисәкчә

в) иярtүче теркәгеч

8. Сорау җөмләне белдерә торган чара дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Авыр йөк белән бу “елга”ны ничек кичәргә? (Г.Галиев)

а) –ны ә) белән б) –әргә в) ничек

II. Теоретик бирем.

Кисәкчәләр турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. ***(10 балл)***

III. Грамматик һәм иҗади бирем.

Ачык иҗекләрдән генә торган сүзләр кулланып, “Мәктәптә” дигән темага 8 җөмлә языгыз. ***(16 балл)***

Мәктәп сүзенә фонетик анализ ясагыз. ***(3 балл)***

Укытучы сүзен тартым белән төрләндерегез. ***(3 балл)***